**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4334**
**26.05.2023**

«2023 елның иң яхшы сантехнигы»
исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында

Йорт эчендәге су белән тәэмин итү, су бирү, җылылык инженерлык системаларына хезмәт күрсәтүне яхшырту һәм торак-коммуналь хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү максатында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. «2023 елның иң яхшы сантехнигы» исеменә шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) 2023 елның 1 июненнән 2023 елның 16 августына кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) шәһәр конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Идарә оешмаларына, торак милекчеләре ширкәтләренә конкурсны үткәрүдә актив катнашуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 26 маендагы
4334 номерлы карарына
1 нче кушымта

«2023 елның иң яхшы сантехнигы» исеменә шәһәр конкурсы үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәрендә «2023 елның иң яхшы сантехнигы» исеменә конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүнең максаты булып шәһәр торак-коммуналь хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү, су белән тәэмин итү, су бирү, җылылык челтәрләрен карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү һәм шәһәрнең йорт эчендәге инженерлык системаларына хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту тора.

2. Конкурсның төп бурычы булып йорт эчендәге су белән тәэмин итү, су бирү, җылылык инженерлык системаларын карап тоту буенча ремонт эшләренең сыйфатына һәм вакытында башкарылуына таләпчәнлекне арттыру һәм сантехникларның инженерлык системаларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чараларда катнашуы тора.

3. Конкурста 2010 елга кадәр файдалануга тапшырылган торак фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган оешмаларда эшләүче сантехниклар катнаша.

4. Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар (күчермәләр):

1) шәхесне раслаучы документ (паспорт);

2) хезмәт кенәгәсе;

3) хезмәт килешүе;

4) торак оешмасы җитәкчесенең хезмәт күрсәтелә торган күпфатирлы йортларны беркетү турындагы приказы.

5. Заявкада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), эш стажы;

2) катнашучы эшли торган оешманың исеме, почта адресы, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефоны.

6. Конкурс материаллары кире кайтарылмый.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

7. Конкурс ике этапта үткәрелә:

1) район этабы – шәһәрнең тиешле район территорияләрендә җиңүчеләрне билгеләү;

2) шәһәр этабы – шәһәрнең тиешле район территорияләрендә җиңгән катнашучылар арасыннан җиңүчеләрне билгеләү.

8. Конкурсның район этабы 2023 елның 1 июненнән 2023 елның 18 июленә кадәр үткәрелә.

9. Конкурсның район этабын оештыру һәм үткәрү өчен Башкарма комитетның район хакимиятләрте Башлыклары тарафыннан конкурсның район этабын үткәрү буенча конкурс комиссияләре (алга таба – район конкурс комиссияләре) төзелә.

10. Район конкурс комиссияләре түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсның потенциаль катнашучыларына конкурсның район этабын үткәрү турында хәбәр итә;

2) 2023 елның 1 июненнән 2023 елның 13 июненә кадәр конкурста катнашуга ирекле формадагы язмача заявкалар кабул итә;

3) әлеге нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән бәяләү критерийлары нигезендә, конкурста катнашуга заявка биргән катнашучыларны бәяли;

4) конкурсның район этабына йомгак ясый һәм конкурсның шәһәр этабында катнашу өчен өч җиңүчене сайлап ала;

5) массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен, конкурсның район этабын үткәрү һәм аның йомгаклары турында мәгълүмат бирә;

6) 2023 елның 20 июленнән соңга калмый, конкурс документларын составы Башкарма комитет карары белән раслана торган шәһәр конкурс комиссиясенә тапшыра.

11. Конкурсның район этабы йомгаклары район конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Конкурсның шәһәр этабы 2023 елның 26 июленнән 2023 елның 16 августына кадәр үткәрелә.

13. Шәһәр конкурс комиссиясе түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) әлеге нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән катнашучылар сыйфатын бәяләү критерийлары нигезендә, конкурсның район этабында катнашкан җиңүчеләрне бәяли;

2) конкурсның шәһәр этабына йомгак ясый;

3) массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен, конкурсның шәһәр этабын үткәрү һәм аның йомгаклары турында мәгълүмат бирә;

4) конкурс материалларының сакланышын тәэмин итә.

14. Конкурсны үткәрү чорында район конкурс комиссияләре һәм шәһәр конкурс комиссиясе урынга барып йорт яны территорияләрен карый.

15. Конкурста катнашучылар район конкурс комиссияләре һәм шәһәр конкурс комиссиясе тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча ун баллы системада бәяләнә:

1) су үткәрү һәм канализация системаларын монтажлау буенча төзү-монтажлау эшләрендә зур кимчелекләр булмау, җылыту приборларындагы төзек булмаган краннарны вакытында ремонтлау һәм алмаштыру – 1 дән 10 баллга кадәр;

2) подвал бүлмәләрен тиешле тәртиптә тоту (подвалга төшү юлы култыксалар белән җиһазландырылган, үткәргеч торбалар аша чыгу өчен күперчекләр булу) – 1 дән 10 баллга кадәр;

3) җылытыла торган бүлмәләрдәге һава температурасын, җылылык системасына килә һәм кире китә торган суның температурасын саклау – 1 дән 10 баллга кадәр;

4) үткәргеч торба һәм канализация өслегендә конденсат булмау – 1 дән 10 баллга кадәр;

5) таләп ителә торган басымны саклау, су белән тәэмин итү, су бирү, җылылык системаларының герметиклыгы – 1 дән 10 баллга кадәр;

6) вазыйфаи инструкция булу, вазыйфаи бурычларны белү – 1 дән 10 баллга кадәр.

Вазыйфаи инструкция булмау билгене 10 баллга киметә; вазыйфаи бурычларны канәгатьләнерлек кенә белү билгене 2 баллга киметә; вазыйфаи бурычларны белмәү билгене 5 баллга киметә;

7) сантехник эшендә кирәкле инструментлар булу – 1 дән 10 баллга кадәр;

8) эшли торган җылылык узелында эш буенча инструкцияләр, эшли торган җылылык узелының схемалары булу – 1 дән 10 баллга кадәр;

9) наемга алучыларның үткәргеч торбалардагы һәм канализациядәге төзексезлекләрне бетерүгә кагылышлы заявкалары буенча шикаятьләр булмау – 1 дән 10 баллга кадәр;

10) сантехникның пөхтә тышкы кыяфәте – 1 дән 10 баллга кадәр.

Конкурс үткәрү чорында башкарыла торган эш төрләре буенча кимчелекләрнең һәр теркәлгән очрагы өчен билге 10 баллга кими.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

16. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча, шәһәр конкурс комиссиясе тарафыннан конкурсның беренче, икенче һәм өченче урыннарын бирү турында карар кабул ителә.

17. Шәһәр конкурс комиссиясенең карары 2023 елның 16 августында комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Шәһәр конкурс комиссиясенең фактта катнашучы әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

18. Шәһәр конкурс комиссиясенең карары 2023 елның 17 августына кадәр кабул ителә һәм 2023 елның 12 сентябренә кадәр массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

19. Конкурста максималь балл җыйган катнашучы конкурсның җиңүчесе була, аңа «2023 елның иң яхшы сантехнигы» исеме бирелә.

20. Конкурс нәтиҗәләре 2023 елның 30 августында үткәрелә торган шәһәр чәчәкләр фестивалендә игълан ителә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева